Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районынң Әлмәт шәһәр Советы
КАРАРЫ

11 май 2018 ел №116

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районының Әлмәт шәһәр Советы
Уставына үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга үзгәрешләр кертелү белән бәйле рәвештә, 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль Закон, 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ санлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставының XV бүлеге нигезендә һәм Әлмәт шәһәре прокурорының 2017 елның 21 декабрендәге 456пр санлы протестын, Әлмәт шәһәре прокурорының 2018 елның 27 февралендәге 134 санлы күрсәтмәсен карап тикшергәннән соң, 2018 елның 26 гыйнварындагы халык тыңлаулары нәтиҗәләрен, ТР Юстиция министрлыгының 2018 елның 4 гыйнварындагы 11-09/2 санлы хатын исәпкә алып,

Әлмәт шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне кушымта нигезендә кабул итәргә.
2. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә юлларга.
3. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Уставына үзгәрешләрне, теркәгәннән соң, «Альметьевский вестник» һәм «Әлмәт таңнары» газеталарында бастырып чыгарырга, «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Әлмәт муниципаль районы сайтында урнаштырырга.
4. Әлеге карар 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 44 нче маддәсе, 8 нче өлеше нигезендә үз көченә керә.
5. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәре Уставының 66.1 маддәсе 2 нче өлешендәге 13,14 нче пунктлар, 2017 елның 29

декабрендәге 463-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, 2018 елның 28 июненнән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

6. Әлмәт шәһәре Уставының 6 нчы маддәсе 1 нче өлеше 5 нче пунктындагы, 45 нче маддәсе 1 нче өлешендәге 4 нче пунктның 7 нче абзацындагы үзгәрешләр, 2017 елның 29 декабрендәге 443-ФЗ санлы «РФдә юл хәрәкәтен оештыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, 2018 елның 30 декабреннән барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәт-ләргә кагыла; Әлмәт шәһәре Уставының 6 нчы маддәсе 1 нче өлеше 19 нчы пунктындагы, 45 нче маддәсе 1 нче өлешендәге 6 нчы пунктның 2 нче абзацындагы үзгәрешләр 2017 елның 31 декабрендәге 503-ФЗ санлы «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы Федераль законга һәм Россия Федерациясенең аерым закон чыгару актларына үзгәрешләр кертү турында»гы Федераль закон үз көченә керүне исәпкә алып, 2019 елның 1 гый-нварыннан барлыкка килгән хокукый мөнәсәбәтләргә кагыла.

7. Карарның үтәлешенә контрольлек итүне Әлмәт муниципаль районының Әлмәт шәһәре башлыгы урынбасары А.М. Токаревка йөкләргә.

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин

Татарстан Республикасы Әлмәт
муниципаль районы Әлмәт шәһәр
Советының 2018 елның 11 маендагы
116 санлы карарына кушымта

Татарстан Республикасы
Әлмәт муниципаль районы Әлмәт шәһәр Советы
Уставына үзгәрешләр

1) 6 нчы маддәнең 1 нче өлешендә:

а) түбәндәге эчтәлектәге 4.1 пункты белән тулыландырырга:

«4.1) җылылык белән тәэмин итүнең бәяле зоналарында җылылык белән тәэмин итүче бердәм оешманың җылылык белән тәэмин итү объектларын төзү, реконструкцияләү һәм (яки) модернизацияләү буенча җылылык белән тәэмин итү системасын үстерү, аның ышанычлылыгын һәм энергетик нәтиҗәлелеген арттыру өчен кирәк булган һәм «Җылылык белән тәэмин итү турында»гы Федераль закон белән билгеләнгән вәкаләтләр чикләрендә җылылык белән тәэмин итү схемасында аның өчен билгеләнгән чараларны үтәвенә муниципаль контрольне тормышка ашыру;»;

б) түбәндәге эчтәлектәге 4.2 пункты белән тулыландырырга:

«4.2) стратегик планлаштыру өлкәсендә 2014 елның 28 июнендәге 172-ФЗ санлы «Россия Федерациясендә стратегик планлаштыру турында»гы Федераль законда күздә тотылган вәкаләтләр;»;

в) 5 нче пунктта «шәһәр чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына» дигән сүзләрдән соң «, юл хәрәкәтен оештыру» дигән сүзләрне өстәргә;

г) 19 нчы пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«19) каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау буенча эшчәнлекне оештыруда катнашу;»;

д) 20 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«20) шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен раслау, аларның үтәлешенә контрольне тормышка ашыру, күрсәтелгән кагыйдәләр нигезендә шәһәр территориясен төзекләндерүне оештыру, шулай ук шәһәр урманнарыннан, шәһәр чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңартуны оештыру»;

е) 6 нчы маддәнең 1 нче өлеше 41 нче пунктындагы «Күчемсез милек дәүләт кадастры турында» дигән сүзләрне «Кадастр эшчәнлеге турында» дигән сүзләр белән алыштырырга;

2) 7 нче маддәнең 1 нче өлешендә:
а) 12 нче пунктны алып ташларга;

б) түбәндәге эчтәлектәге 16 нчы пункт белән тулыландырырга:
«16) инвалидларга, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә физик культура һәм спортны, адаптив физик культура һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтү.»;

3) 10 нчы маддәнең 8 нче пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:
«8) халык тыңлаулары, җәмәгатьчелек фикер алышулары;»;

4) 17 нче маддәдә:
4.1) Маддә исемен түбәндәге укылышта бәян итәргә:
«17 нче маддә. Халык тыңлаулары, җәмәгатьчелек фикер алышулары»;

4.2) 3 нче өлешне:
а) түбәндәге эчтәлектәге 2.1 пункты белән тулыландырырга:
«2.1) шәһәрнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты;»;

б) 3 нче пунктны көчен югалткан дип санарга;

4.3) 4 нче өлешендә «Халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе» дигән сүзләрне «әлеге маддәнең 3 нче өлешендә күрсәтелгән проектлар һәм мәсьәләләр буенча халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе,» дигән сүзләр белән алыштырырга;

4.4) түбәндәге эчтәлектәге 5 нче өлеш белән тулыландырырга:
«5. Генераль планнар проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару проектлары, территорияне планлаштыру проектлары, территорияне межалау проектлары, территорияләрне төзекләндерү кагыйдәләре проектлары, күрсәтелгән расланган документларның берсенә үзгәрешләр кертүне күздә тотучы проектлар, җир участогыннан яки капиталь төзелеш объектыннан файдалануның шартлы рөхсәт ителгән төренә рөхсәт бирү турындагы карарлар проектлары, рөхсәт ителгән төзелеш, капиталь төзелеш объектларын реконструкцияләүнең чик параметрларыннан тайпылуга рөхсәт бирү турындагы карарлары проектлары, җирдән файдалану һәм төзелеш алып баруның расланган кагыйдәләре булмаганда җир участокларыннан һәм капиталь төзелеш объектларыннан файдалануның рөхсәт ителгән бер төрен файдалануның икенче төренә үзгәртү мәсьәләләре буенча җәмәгатьчелек фикер алышулары яки халык тыңлаулары үткәрелә, аларны оештыру һәм үткәрү тәртибе шәһәр төзелеше эшчәнлеге турындагы законнар положениеләрен исәпкә алып шәһәр Советы норматив хокукый акты белән билгеләнә.»;

5) 26 нчы маддәне түбәндәге эчтәлектәге 10, 11, 12, 13 нче өлешләр белән тулыландырырга:

«10. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары биналарда, махсус билгеләнгән урыннарда, шулай ук ишегалды эчендәге территорияләрдә аларны үткәрү тормыш-яшәеш, транспорт яки социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшчәнлеге бозылуга китермәү, җәяүлеләрнең һәм (яки) транспорт чараларының хәрәкәтенә, я булмаса гражданнарның торак биналарга яки транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керә алуына комачаулык тудырмау шарты белән үткәрелә. Андый очрашулар турында ТР башкарма власть органнарына яки җирле үзидарә органнарына хәбәр итү таләп ителми. Бу вакытта депутат күрсәтелгән органнарга очрашуларны үткәрү көне һәм вакыты турында алдан хәбәр итәргә хаклы.

11. Шәһәр башкарма комитеты депутатларның сайлаучылар белән очрашулары өчен махсус билгеләнгән урыннарны бүлеп бирә, шулай ук депутатларның сайлаучылар белән очрашуларын үткәрү өчен җирле үзидарә органнары тарафыннан бирелә торган биналарның исемлеген, аларны бирү тәртибен билгели.

12. Депутатның сайлаучылар белән очрашулары Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, шествиеләр һәм пикет үткәрү турындагы законнары нигезендә ачык чара рәвешендә үткәрелә.

13. Депутатның Россия Федерациясенең җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, шествиеләр һәм пикет үткәрү турындагы законнары нигезендә ачык чара рәвешендә сайлаучылар белән очрашулар оештыруына яки үткәрүенә каршылык тудырган өчен Россия Федерациясе законнары нигезендә административ җаваплылык каралган.»;

6) 29 нчы маддәнең 1 нче өлеше 6 нчы пунктын түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«6) шәһәрнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен раслау;»;

7) 42 нче маддәнең 4 нче өлешен түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Президентының (ТР дәүләт власте югары башкарма органы җитәкчесенең) шәһәр башлыгын вазифасыннан азат итү турындагы хокукый акты яки шәһәр Советының шәһәр башлыгын отставкага җибәрү турындагы карары нигезендә вәкаләтләре срогыннан алда туктатылган шәһәр башлыгы әлеге хокукый актны яки карарны суд тәртибендә гамәлдән чыгарса, шәһәр Советы суд карары законлы көченә кергәнче шәһәр Советы тарафыннан үз составыннан сайлана торган шәһәр башлыгын сайлау турында карар кабул итәргә хаклы түгел.»;

8) 45 нче маддәнең 1 нче өлешендә:

8.1) 1 нче пунктны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«1) планлаштыру, бюджет, финанслар һәм исәпкә алу өлкәсендә:

- шәһәр бюджеты проектын (бюджет һәм уртача сроклы финанс планы проектын) төзүне тәэмин итә;

- шәһәр бюджеты проектын кирәкле документлары һәм материаллары белән берлектә шәһәр Советы раславына кертә;

- РФ Бюджет кодексы нигезендә бюджетара трансфертларны бүлү методикаларын һәм (яки) бирү тәртипләрен эшли һәм раслый;

- шәһәр бюджеты үтәлешен һәм бюджет отчетларын төзүне тәэмин итә, шәһәр бюджетының үтәлеше турындагы отчетны шәһәр Советы раславына тапшыра;

- муниципаль бурыч белән идарә итүне тәэмин итә;

- шәһәрнең социаль-икътисади үсеш стратегиясен эшләүне һәм тормышка ашыруны тәэмин итә;

- шәһәр бюджеты үтәлешен оештыра;

- шәһәр бюджеты үтәлеше турындагы отчетларны хәзерләүне тәэмин итә;

- шәһәр икътисады һәм социаль өлкә торышын характерлаучы статистик күрсәткечләрне җыюны һәм әлеге мәгълүматларны РФ Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән тәртиптә дәүләт власте органнарына тапшыруны оештыра;»;

8.2) 45 нче маддәнең 1 нче өлешендәге 3 нче пунктның уникенче абзацында «Күчемсез милек дәүләт кадастры турында» дигән сүзләрне «Кадастр эшчәнлеге турында» дигән сүзләр белән алыштырырга.

8.3) 4 нче пунктның җиденче абзацын «шәһәр чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларының сакланышына» дигән сүзләрдән соң «, юл хәрәкәтен оештыру» дигән сүзләр белән тулыландырырга;

8.4) 5 нче пунктны түбәндәге эчтәлектәге тугызынчы абзац белән тулыландырырга:

«- инвалидларга, сәламәтлек буенча мөмкинлекләре чикләнгән кешеләргә физик культура һәм спортны, адаптив физик культура һәм адаптив спортны үстерүгә булышлык күрсәтә;»;

8.5) 6 нчы пунктта:

а) икенче абзацны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«- каты коммуналь калдыкларны туплау (шул исәптән аерым туплау) һәм транспортлау буенча эшчәнлекне оештыруда катнаша;»;

б) өченче абзацны түбәндәге укылышта бәян итәргә:

«- шәһәр территориясен төзекләндерүне оештыруны, төзекләндерү кагыйдәләренең үтәлешенә контрольлек итүне, шулай ук шәһәр урманнарыннан, шәһәр чикләрендә урнашкан аеруча саклана торган табигать территорияләрендәге урманнардан файдалану, аларны саклау, яклау, яңартуны тәэмин итә»;

9) 49 нчы маддәнең 4 нче пунктында «шәһәрнең комплекслы социаль-икътисади үсеш планнары һәм программалары проектлары һәм аларның үтәлеше турындагы отчетлар» дигән сүзләрне «шәһәрнең социаль-икътисади үсеш стратегиясе проекты» дигән сүзләр белән алыштырырга;

10) 64.2 маддәсен түбәндәге эчтәлектәге 3 нче өлеш белән тулыландырырга:

«3. Муниципаль вазифа биләүче кешегә карата коррупцион хокук бозу кылган өчен ышаныч югалу белән бәйле рәвештә эштән азат итү (вазифасыннан азат итү) рәвешендә җәза куллану турындагы белешмәләр әлеге зат тиешле вазифа биләгән җирле үзидарә органы тарафыннан 2008 елның 25 декабрендәге 273-ФЗ санлы «Коррупциягә каршы тору турында»гы Федераль законның 15 нче маддәсендә күздә тотылган, ышаныч югалу белән бәйле рәвештә азат ителгән кешеләр реестрына кертелә.»;

11) XI бүлекне түбәндәге эчтәлектәге 66.1 маддәсе белән тулыландырырга:

«66.1 маддәсе. Шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре эчтәлеге

1. Шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре шәһәр Советы тарафыннан раслана.

2. Шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре түбәндәге мәсьәләләрне җайга сала ала:

1) гомуми файдаланудагы территорияләрне карап тоту һәм андый территорияләрдән файдалану тәртибе;

2) биналар, корылмалар, төзелешләр фасадларының һәм койма конструкцияләренең тышкы кыяфәте;

3) төзекләндерү элементларын проектлау, урнаштыру, карап тоту һәм торгызу, шул исәптән җир казу эшләре башкарганнан соң;

4) шәһәр территориясен яктыртуны оештыру, биналар, корылмалар, төзелешләрнең архитектур яктыртылышын да кертеп;

5) торак пунктлар чикләрендә урнашкан газоннар, чәчәк түтәлләре, үләнле үсемлекләр үскән башка территорияләрне булдыру, карап тоту, торгызу һәм саклау тәртибен дә кертеп, шәһәр территориясен яшелләндерүне оештыру;

6) шәһәр территориясендә мәгълүмат урнаштыру, шул исәптән урам исемнәре һәм йорт номерлары күрсәткечләрен, алтакталар урнаштыру;

7) балалар өчен һәм спорт мәйданчыклары, йорт хайваннарын йөртү өчен мәйданчыклар, парковкалар (туктау урыннары), кече архитектур формалар урнаштыру һәм карап тоту;

8) җәяүлеләр өчен коммуникацияләрне, шул исәптән тротуарлар, аллеялар, сукмаклар оештыру;

9) инвалидларга һәм халыкның башка аз хәрәкәтләнүче төркемнәренә шәһәр территориясендә каршылыкларсыз хәрәкәт итү максатларында уңайлыклар булдыру;

10) шәһәр территориясен җыештыру, шул исәптән кышкы чорда да;

11) яңгыр сулары агу урыннары булдыру;

12) җир казу эшләре башкару тәртибе;

13) биналар, корылмалар, төзелешләр, җир участоклары милекчеләренең һәм (яки) башка законлы хуҗаларының (йорт астындагы җир участоклары теркәлмәгән яки андый йортлар чикләре эчендә теркәлгән күпфатирлы йортларда бина милекчеләреннән һәм (яки) башка законлы хуҗаларыннан кала)

якын-тирәдәге территорияләрне карап тотуда катнашуы, шул исәптән финанс ягыннан да;

14) ТР законы белән билгеләнгән тәртип нигезендә якын-тирәдәге территорияләрнең чикләрен билгеләү;

15) шәһәр территориясен бәйрәмчә бизәү;

16) гражданнарның һәм оешмаларның шәһәр территориясен төзекләндерү буенча чараларны тормышка ашыруда катнашуы;

17) шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләрен үтәүгә контрольне тормышка ашыру.

3. Аерым муниципаль берәмлекләрнең табигать-климатик, географик, социаль-икътисади һәм башка үзенчәлекләреннән чыгып, Татарстан Республикасы Законында шәһәр территориясен төзекләндерү кагыйдәләре белән көйләнә торган башка мәсьәләләр дә күздә тотыла ала.»;

12) 72 нче маддәнең 3 нче өлешен түбәндәге эчтәлектәге абзацлар белән тулыландырырга:

«Муниципаль хокукый актны яки җирле үзидарә органнары арасында төзелгән килешүне рәсми бастырып чыгару булып аның тулы текстын шәһәрдә тарала торган вакытлы басма матбугатта беренче басылуы санала.

Муниципаль хокукый актларны һәм килешүләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) өчен җирле үзидарә органнары шулай ук челтәр басмасыннан да файдаланырга хокуклы. Муниципаль хокукый актның тулы тексты рәсми челтәр басмасында басылып чыккан да (урнаштырылганда) аңа күләмле график һәм таблица кушымталары әлеге басмада китерелмәскә дә мөмкин.».

Шәһәр башлыгы А.Р. Хәйруллин